# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге составына керүче Яңа Мочалкино торак пунктында 2022 елга үзарасалым кертү турында

№ 3 10 ноябрь 2021 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, «Татарстан Республикасындаҗирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нчестатьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясынигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлегенең Яңа Мочалкино торак пунктында узган гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге Яңа Мочалкино торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күпбалалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2022 елда 500(биш йөз) сум күләмендә үзарасалым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- Яңа Мочалкино авылы торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту(килешү буенча эш өчен түләү);
- Яңа Мочалкино торак пунктында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (махсус җиһазлар, лампалар сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү).

3.Әлеге карарны Шәдче авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнарҗыенындарәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Шәдче авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе В.В.Шрыков